| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

06.04.2021 № 172-р

2021 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49 статьясына таянып, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының югарыда аталган законга кушымтада бәян ителгән иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем һәм Дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында» 2006 ел, 23 июнь, 694 нче карары нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

БОЕРЫК БИРӘ:

1. 2021 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. . Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1 ялгыз яшәүче гражданин өчен – 732081,90 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 931740,60 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 1197952,20 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 1597269,60 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 1996587,00 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 2395904,40 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 2795221,80 сум;

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 15835,14 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 10076,91 сум;

1.2.3. өч кеше һәм аннан да күбрәк гаилә өчен – 8637,35 сум.

2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән башлап Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләү турында» 2020 елның 30 апрелендәге 188/1-р номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин